СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№6-32 от «29» марта 2019 г.

Мамадыш муниципаль районы Советының
2018 елның 19 ноябрендәге 7-29 номерлы карары белән расланган Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, “Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 ел, 06 октябрь, 131 -ФЗ санлы Федераль законы, “Коррупциягә каршы тору турында”гы 2008 ел, 25 декабрь, 273-ФЗ Федераль законы , Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Советы Мамадыш муниципаль районы к а р а р к а б у л и т т е

1.Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 ноябрендәге 7-29 номерлы карары белән расланган Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Әлеге Нигезләмәнең 3 бүлеген түбәндәге эчтәлектәге 3.2.6 пункты белән тулыландырырга:

«3.2.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3 һәм 3.2.4 пунктларында каралган дәлилләнгән нәтиҗәләр түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) Әлеге Нигезләмәнең 3.1.пунктының «б» һәм «д» пунктчаларының икенче һәм бишенче абзацларында бәян ителгән мөрәҗәгатьләр һәм белдерүләрдә күрсәтелгән мәгълүматны;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан мөрәҗәгатьләр нигезендә алынган мәгълүмат;

в) Әлеге Нигезләмәнең 3.1.пунктының «б» һәм «д» пунктчаларының икенче һәм бишенче абзацларында бәян ителгән мөрәҗәгатьләр һәм белдерүләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән йомгаклау, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3, 3.11 пунктлары нигезендә карарлар кабул итү өчен тәкъдимнәрне.»

2. Әлеге карарны интернет мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

000014

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советының регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов